| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОСЛЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЭСЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.09.2021 Иске Эсләк авылы № 16

Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Типлаштырылган регламентлар турында» 2021 елның 09 июлендәге 04-51/4811 номерлы соравын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 24 июлендәге 12 номерлы карары;

- «Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 24 июлендәге 12 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 2 июлендәге 20 номерлы карары.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе И.Н.Гафаров

Исполнительный комитет Старосляковского сельского поселения
Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитеты